Никольский авыл җирлеге башкарма комитеты

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы

КАРАР

23.07.2021 ел № 18

Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 210-ФЗ Федераль кануннары һәм гражданнарга муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында ТР Спас муниципаль районының Никольск авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында - http:/ www.spasskiy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Никольский авыл җирлеге башлыгы Е.А.Синицин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИКОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ